ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_24.01.2020 г.____ Мөслим № _38_

**Белем бирү оешмаларын
Татарстан Республикасы Мөслим
муниципаль районы территорияләренә беркетү турында**

Мөслим муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарны муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә кабул итүне тәэмин итү максатларында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 8 өлеше һәм 67 статьясындагы 3 өлеше нигезендә һәм РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында»гы боерыгы белән Мөслим муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Белем бирү оешмаларын 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә Мөслим муниципаль районы территорияләренә беркетергә.

2. Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

2.1. Мәгълүматны белем бирү процессында катнашучыларга белем бирү учреждениесенең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән җиткерергә.

2.2. Мөслим муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетелгән төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы Р.Т.Демидовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы** **Р.А. Ильясов**